КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 27 ноябрь г.Казань № 1137

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 елда Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасы алдындагы йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү кагыйдәләрен раслау хакында» 2013 ел, 15 февраль, 106 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 елда Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасы алдындагы йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү кагыйдәләрен раслау хакында» 2013 ел, 15 февраль, 106 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2013 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «2013 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган 2013 елда Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасы алдындагы йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү кагыйдәләрендә:

исемендә «2013 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «2013 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Бурычлы оешма бюджет кредиты буенча реструктуризацияләнгән бурычларны каплау һәм (яки) түләүләрне кичектереп торган өчен процентлар түләү вакытларын бозган очракта, бурычлы оешма әлеге йөкләмәләрнең үтәлешен кичектереп торган һәр көн өчен 10 мең сум күләмендә пеня түли.

Әгәр әлеге йөкләмәне үтәү вакыты башланган көннән 14 эш көне узгач та йөкләмә үтәлмәсә, бюджет кредиты буенча төп бурыч һәм процентлар буенча капланмаган реструктуризацияләнгән бурычлар, шулай ук өлешләп түләгән өчен исәпләнгән процентлар бурычлы оешма тарафыннан вакытыннан алда берьюлы түләнергә тиеш. Бер үк вакытта әлеге чор өчен пеня түләнергә тиеш.»;

13 пунктның «б» пунктчасында «20 декабрьдән дә соңга калмыйча» сүзләрен «чираттагы финанс елына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карар раслаганнан соң 14 эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Бурычлы оешма тарафыннан бу Кагыйдәләрнең 13 пунктында каралган йөкләмәләр үтәлмәгән очракта, бурычлы оешма әлеге йөкләмәләрне үтәү вакытын кичектергән һәр көн өчен 5 мең сум күләмендә пеня түли.

Әгәр бу Кагыйдәләрнең 13 пунктындагы «а» һәм «в» пунктчаларында каралган йөкләмәләрне үтәү сроклары башланган көннән соң ике ай узгач та алар үтәлмәгән булса, бурычлы оешма бюджет кредиты буенча капланмаган реструктуризацияләнгән бурычларны һәм өлешләп түләгән өчен процентларны вакытыннан алда берьюлы каплый, шулай ук кредит буенча процентларны Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына тиешле бюджет кредитын бирү турындагы шартнамәдә билгеләнгән күләмдә, аннан тиешле чорда бурычлы оешма фактта түләгән түләүне кичектереп торган өчен процентлар суммаларын чигереп түли. Бер үк вакытта әлеге чор өчен пеня түләнергә тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле 15 һәм 16 пунктлар өстәргә:

«15. Бу Кагыйдәләрнең 2 пункты нигезендә бюджет кредиты буенча реструктуризацияләнгән бурычларны каплау чоры 2021 елда бурычлы оешма гаризасы нигезендә 2025 елдан 2034 елга (2034 елны кертеп) кадәрге чорга ел саен тигез өлешләр белән түләү һәм әлеге бурычларны вакытыннан алда түләү мөмкинлеге белән күчерелергә тиеш.

16. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, бу Кагыйдәләрнең 11, 13 һәм 14 пунктларында каралган очракларда, бюджет кредитлары буенча вакытында түләнмәгән бурычларны һәм (яки) йөкләмәләрне үтәмәгән өчен пеняларны түләттерү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чараларны күрә.».

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры            А.В.Песошин